ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2017 ел № 16/6

Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын җайга салу өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 10 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 752 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында» 1072 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 145 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 24 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында 678 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 146 санлы Карары, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 10 июлендәге 31/7 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктта:

- тугызынчы абзацта «урта (тулы) гомуми белем һәм башлангыч һөнәри белем, - 1,050» сүзләрен «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) хәзерләү программалары буенча урта гомуми белем һәм урта һөнәри белем, - 1,347» сүзләренә алыштырырга;

- унынчы һәм унберенче абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белемгә ия хезмәткәрләр өчен, - 1,570;

аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр» квалификациясен бирү белән раслanучы югары белемгә ия хезмәткәрләр өчен, - 1,647;»;

- унөченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«йомгаклау аттестациясен уңышлы узган затка «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән раслanучы югары белемгә ия хезмәткәрләр өчен, - 1,570;»;

2) 7 пунктның 2 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2 таблица

Башкару сәнгәте хезмәткәрләренә хезмәткә түләү буенча
разрядлар билгеләү өчен нигезләр

| Хезмәткә түләү разряды | Тиешле вазифаны биләү өчен кирәкле белем дәрәҗәсе |
|---|---|
| 1 | Төп гомуми һәм урта гомуми белем |
| 2 | Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белем |
| 3 | Югары белем – бакалавриат |
| 4 | Югары белем – специалитет яки магистратура»; |

3) 9 пунктны яңа редкациядә бәян итәргә:

«9. Әгәр биләгән вазифа югары белем – бакалавриат яисә специалитет яки магистратура, урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, югары белемле затлар тарафыннан биләнгән вазифалар буенча – бакалавриат яисә специалитет яки магистратура, урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белем таләп ителмәгән очракта, урта гомуми белемгә туры килүче хезмәткә түләү разряды билгеләнә.»;

2. Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/8 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 10 июлендәге 31/7, 2014 елның 9 декабрендәге 35/7 санлы Карарлары редакциясендә) Муниципаль китапханәләр, музейлар һәм мәдәният-ял муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) тугызынчы абзацта «башлангыч һөнәри белем, – 1,050» сүзләрен «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белем – 1,347» сүзләренә алыштырырга;

2) унынчы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белемгә ия хезмәткәрләр өчен, – 1,570»;

3) унберенче абзацта «1, 284» саннарын «1,647» саннарына алыштырырга;

4) унөченче абзацта «1,224» саннарын «1,570» саннарына алыштырырга.

3. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта:

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i},»;$$

- җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«8. Мәгариф һәм мәктәпкәчә белем оешмалары, сәнгать-эстетика, күппрофильле һәм спорт юнәлешендә өстәмә белем оешмалары, һөнәри мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәренең нигез оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_b = T_1 \times K_{m_i} \times K_{m_j} + P,$$

биредә:

$K_{m_j}$ – өлкә приоритетының артучы коэффициенты;

$P$ – китап бастыру продукциясе һәм периодик басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация укыту нагрузкасына пропорциональ рәештә билгеләнә, ләкин бер ставкадан артык түгел.

Өлкә приоритетының артучы коэффициенты педагогик хезмәткәрләрнең нигез окладын исәпләп чыгару өчен кулланыла һәм түбәндәгене тәшкил итә:

мәктәпкәчә белем оешмаларында:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) хәзерләү программалары буенча төп гомуми белемгә, урта гомуми белемгә һәм урта һөнәри белемгә ия хезмәткәрләр өчен, – 1,000;

урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белемгә ия хезмәткәрләр өчен, – 1,166;

югары белемгә – бакалавриат – ия хезмәткәрләр өчен, – 1,223;

югары белемгә – специалитет яки магистратура – ия хезмәткәрләр өчен, – 1,166;

гомуми белем оешмаларында:

беренче, икенче, өченче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр

вазифаларының һөнәри квалификацион төркеме хезмәткәрләре өчен:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) хәзерләү программалары буенча төп гомуми белемгә, урта гомуми белемгә һәм урта һөнәри белемгә ия булганнарга, – 1,000;

урта звено белгечләрен хәзерләү программалары буенча урта һөнәри белемгә ия булганнарга, – 1,200;

югары белемгә – бакалавриат – ия булганнарга, – 1,258;

югары белемгә – специалитет или магистратура – ия булганнарга, – 1,200;

дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификацион төркеме хезмәткәрләре өчен – 1,029;

сәнгать-эстетика, күппрофильле һәм спорт юнәлешендә өстәмә белем оешмаларында – 1,565;».

4. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге 9/8 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Муниципаль учреждениеләрнең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренә түләү шартлары турында нигезнамәнең 7 пунктына, җиденче абзацта «1,155» саннарын «1,565» саннарына алыштырып, үзгәрешләр кертергә.

5. Әлеге Карарның көче 2017 елның 1 мартында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләрнә кагыла, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керүче 1 пунктның 2, 3 пунктчаларыннан тыш.

6. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ